ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

« 13 » май 2024 ел № 321

**«Муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына кергән инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидлар торагын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында» 2017 елның 14 мартындагы 262 номерлы Башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү хакында (04.12.2018 №1207 үзгәрешләр белән)**

«Ватанны саклаучылар» МХОдә катнашучыларга ярдәм дәүләт фондын төзү турында» 2023 елның 3 апрелендәге 232 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып, күпфатирлы йортта торакны һәм гомуми мөлкәтне җайлаштыру чаралары турында» 2016 елның 09 июлендәге 649 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары һәм «Татарстан Республикасы дәүләт торак фонды, муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына кергән торакка карата инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып, инвалидлар торагын җайлаштыру чараларын координацияләү буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органын билгеләү турында» 2016 елның 20 декабрендәге 958 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына кергән инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидлар торагын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия төзү турында» 2017 елның 14 мартындагы 262 номерлы Башкарма комитет карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) «Муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына кергән инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидлар торагын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия составын әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.М. Хәсәновка йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
"_13_" _05_ 2024 ел, №321
карарына кушымта

Муниципаль торак фонды, шулай ук шәхси торак фонды составына кергән инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидлар торагын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча муниципаль комиссия составы

| | |
|---|---|
| Галимуллин И.Ә. | - комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары; |
| Хәсәнов И.М. | - комиссия секретаре, Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| *Комиссия әгъзалары:* | |
| Хәмидуллина Р.Ш. | - Ветераннар Советы рәисе, ТР Арча муниципаль районының Инвалидлар җәмгыяте рәисе (килешү буенча); |
| Мифтахетдинова Н.Р. | - Татарстан Республикасы кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкиленең Арча муниципаль районындагы җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча); |
| Касыймов Р.Ф. | - Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Әгълиев И.К. | - «Идарәче компания» ҖЧҖ директоры (килешү буенча); |
| Ибраһимова Д.М. | - Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Гарифуллина А.Р. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге ТКХ, энергетика һәм элемтә секторы мөдире; |
| Һидиятуллин М.И. | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге шәһәр төзелеше һәм архитектура секторы мөдире; |
| Шәяхмәдова А.Р. | - Татарстан Республикасы буенча «Ватанны саклаучылар» МХОдә катнашучыларга ярдәм дәүләт фонды филиалы |

| | |
|---|---|
| | вәкиле, инвалидлар белән эшләү секторының социаль координаторы (килешү буенча); |
| Хафизов И.И. | "Барыбыз өчен дә ачык дөнья" БИҖ эксперты (килешү буенча). |

Җирле үзидарә органыннан җаваплы вәкил (килешү буенча).